| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ<br>ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ<br>И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ<br>ЭШЛӘРЕҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ<br>ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |

---

| | | |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| 17.03.2016 | | 110 |

**Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында кагыйдәнамәне раслау турында**

"Коррупциягә каршылык турында" 2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ Федераль законын, "Русия Федерациясе аерым дәүләт вазифаларында, федераль дәүләт хезмәте вазифаларында булган шәхесләр һәм башка шәхесләр белән вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында" 2015 ел 22 нче декабрь № 650 Русия Федерациясе Президенты Указын үтәү йөзеннән коррупциягә каршылык максаты белән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында кагыйдәнамәне расларга.

2. Биредәге боерыкны министр урынбасарларына, Татарстан Республикасы ГТХМ аппараты структура бүлекчәләренең җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

3. Биредәге боерыкны башкару контролен министр урынбасары О.А. Степущенкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

17.03. 2016 № 110
Татарстан
Республикасы ГТХМ
боерыгы белән
расланган

**Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында кагыйдәнамә**

1. Биредәге Кагыйдәнамә Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибен билгеләп куя.

2. Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт гражданлык хезмәткәрләре коррупциягә каршылык турында Русия Федерациясе законнарына туры китереп вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай да кызыксыну конфликтларын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар кабул итәргә тиеш.

3. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – министр) исеменә вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр кушымта № 1 туры китереп язу килеш белдерү кебек төзелә һәм дәүләт хезмәткәре вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында белгәндә үк кичектермичә дәүләт гражданлык хезмәткәре белән Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхескә) тапшырыла.

4. Теркәүдән соң теркәлгән хәбәр копиясе имза куйдыртылып эшченең кулына бирелә яисә почта аша бирү турында белдерү белән җибәрелә.

Копиягә хәбәрнең дата һәм теркәү номеры, фамилия, инициаллар, хәбәрне кабул иткән шәхес вазифасы күрсәтүләре белән теркәү турында билге куела.

5. Коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхес биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 2 туры китерелгән теркәү журналында белдерүнең теркәлүен башкара.

Вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында

белдерүләрнең теркәү журналының битләре номерланырга, шнурланырга һәм герблы печать белән кыстырылырга тиеш.

6. Дәүләт гражданлык хезмәткәре хезмәт бурычларын башкармаган вакытта һәм эш урыныннан читтә булганда вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхескә) нинди дә булса мөмкин элемтә чаралары аша белдерергә тиеш, ә хезмәт урынына килгәндә туры килгән хәбәрне язу формасында белдерү кебек төзергә.

Белдерүгә вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү шартларын раслый торган бөтен булган материаллар кушыла.

7. Вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында дәүләт хезмәткәренең белдерүсе яисә мәгълүматы белдерүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгакны әзерли торган коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхес белән карап тикшерелә.

8. Белдерүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән йомгакны әзерләгәндә коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхес белдерүне китергән дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә үткәрергә, аннан язма аңлатма алырга хаклы, ә министр билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына һәм кызыксынган оешмаларга сорау җибәрә ала.

9. Белдерү, шулай да дәлилләнгән йомгак һәм башка материаллар кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенә (коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхескә) килү көненнән алып җиде эш көне эчендә дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы ГТХМ кызыксыну конфликтларын җайга салу буенча комиссия рәисенә китерелә.

Сорауларны җибәргән вакытта белдерү, шулай да дәлилләнгән йомгак һәм башка материаллар белдерү килгән вакыттан алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә китерелә. Билгеләнгән вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артык түгел.

10. Белдерү, йомгак һәм башка материаллар, Татарстан Республикасы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы ГТХМ ның кызыксыну конфликтларын җайга салу буенча комиссия турында Кагыйдәнамәгә туры китереп, комиссия белән карап тикшеренәләр.

11. кабул ителгән карар коррупция һәм башка җинаятьләр профилактикасы өчен җаваплы шәхес белән хәбәрләрне теркәү журналына кертелә һәм имза куйдыртылып яисә эшчегә кабул ителгән карар белән таныштыру фактын билгеләп куя ала торган башка юл белән хәбәрне китергән эшчегә җиткерелә.

Татарстан Республикасы ГТХМ ның
17.03.2016 № 110 боерыгы белән
расланган
Татарстан Республикасы ГТХМ ның
дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән
вазифа бурычларын башкарганда
кызыксыну конфликтларына китерә
торган яисә китерә ала торган шәхси
кызыксыну барлыкка килү турында
хәбәр итү тәртибе турында
кагыйдәнамәгә
Кушымта № 1

Татарстан Республикасы
ГО эшләре һәм ГТХ министрына
Р.Ж. Хәбибуллинга

Вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында
БЕЛДЕРҮ

Вазифа бурычларын башкарганда миндә кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган (кирәклесен ассызырга) шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр итәм.

Шәхси кызыксыну барлыкка килү нигезе булган шартлар: ________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________________

Шәхси кызыксыну вазифа бурычларын башкаруга тәэсир итә торган яисә тәэсир итә ала торган вазифа бурычлары: ____________________________________________________________________________________________________________________

Контфликтны булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________________

Биредәге белдерүне карап тикшергәндә дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм Татарстан Республикасы ГТХМ ның кызыксыну конфликтларын җайга салу буенча комиссия утырышында үзем булырга җыенам (җыенмыйм) (кирәклесен ассызырга).

“__” ___________ 20__ ел  ______________ (шәхес имзасы)  ________________ (имзаны ачыклау)

Белдерүләрне теркәү
журналында теркәү номеры ______________
20__ел

Теркәү датасы ______________
20__ел

Татарстан Республикасы ГТХМ ның
17.03.2016 № 110 боерыгы белән
расланган
Татарстан Республикасы ГТХМ ның
дәүләт гражданлык хезмәткәрләре белән
вазифа бурычларын башкарганда
кызыксыну конфликтларына китерә
торган яисә китерә ала торган шәхси
кызыксыну барлыкка килү турында
хәбәр итү тәртибе турында
кагыйдәнамәгә
Кушымта № 2

Вазифа бурычларын башкарганда кызыксыну конфликтларына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында белдерүләрне теркәү журналы

| № т/б | Белдерүнең теркәү номеры | Белдерүне теркәү датасы | Белдерүне китерүче | | Белдерүне теркәүче | | | Белдерү копиясен алу (копияне алдым, имза) яисә почта аша белдерү кописен җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ф.и.о. | вазифа | ф.и.о. | вазифа | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |